# КАРАР
## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Максабаш торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 8 декабре Максабаш авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Максабаш торак пунктында 2019 елның 7 декабрендә һәм 8 декабрендә узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Максабаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:
- урамнарга вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)түбәндәге урамнар буенча: Газ, Октябрь, Молодежная, Мирная;
-лампалар, урам яктырткычлары, электр җиһазлары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Максабаш авылы янындагы территорияне төзекләндерү (Максабаш авылы, Татарстан урамындагы су башнясы кую урыны);
- юлларны кардан чистарту;
- мотопомпалар сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 218 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 141 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашучы 106 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында 35 кеше «Каршы» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Максабаш торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нтиҗәләре-дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең Максабаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- урамнарга вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)түбәндәге урамнар буенча: Газ, Октябрь, Молодежная, Мирная;
-лампалар, урам яктырткычлары, электр җиһазлары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Максабаш авылы янындагы территорияне төзекләндерү (Максабаш авылы, Татарстан урамындагы су башнясы кую урыны);
- мотопомпалар сатып алу, кабул ителгән

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Интернет челтәрендә Югары Кибәхуҗа авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башлыгы Ф. Р. Мәхмүтов